КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 12 август г.Казань № 798

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 3 апрель, 260 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын тормышка ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 3 апрель, 260 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 2 ноябрь, 983 нче, 2021 ел, 06 ноябрь, 1053 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен һәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә һәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибе;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә һәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе.»;

әлеге карар белән расланган Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибендә:

исемдә «система» сүзеннән соң «күрсәтү» сүзен өстәргә;

2 пунктта:

«система» сүзеннән соң «күрсәтү» сүзен өстәргә;

«2021» саннарын «2025» саннарына алмаштырырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Татарстан Республикасы бюджетының паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерүгә бәйле чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүгә түбәндәгеләр өлешендә акча җибәрә:

а) паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә мохтаҗ пациентларны авыруның авыр симптомнарын җиңеләйтү, шул исәптән авыртуны басар өчен дару препаратлары белән тәэмин итү;

б) «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 5 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 31 маендагы 345н/372н номерлы боерыгы белән расланган медицина оешмаларының, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының һәм иҗтимагый берләшмәләрнең, сәламәтлекне саклау өлкәсендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка коммерциягә карамаган оешмаларның үзара хезмәттәшлеген дә кертеп, паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турындагы нигезләмәдә каралган җиһазлар стандартлары нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы медицина оешмаларын махсуслаштырылган паллиатив медицина ярдәмен күрсәтүче структур бүлекчәләре (алга таба - медицина оешмалары), медицина эшләнмәләре, шул исәптән өйдә файдалану өчен бирелә торган кеше организмы органнары һәм системалары функцияләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән медицина әйберләре белән җиһазлау (яңадан җиһазлау, өстәмә җиһазлау) (алга таба - паллиатив медицина ярдәмен оештыру турындагы нигезләмә);

в) паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турындагы нигезләмәдә каралган балаларга күчмә патронаж паллиатив медицина ярдәме бүлеген җиһазландыру стандарты нигезендә медицина оешмаларын өлкәннәргә һәм җиңел автомашиналарга күчмә патронаж паллиатив медицина ярдәме бүлекчәсен автомобильләр белән тәэмин итү стандарты нигезендә автомобильләр белән тәэмин итү.»;

7.1 - 7.3 пунктларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр бирү турындагы килешүдә билгеләнгән формада һәм срокларда финанслашу максатларында субсидияләр бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында һәм субсидиядән файдалану нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап урнаштыра.»;

күрсәтелгән карарга «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә һәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибен өстәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 3 апрель, 260 нчы карары белән расланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 12 август, 798 нче карары редакциясендә)

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә һәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә һәм «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика балалар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгели (алга таба - тиешенчә учреждениеләр, субсидияләр).

Субсидияләр Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән һәм федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү чараларын гамәлгә ашыруга бирелә.

Субсидияләр «Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 5 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 31 маендагы 345н/372н номерлы боерыгы белән расланган медицина оешмаларының, социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының һәм иҗтимагый берләшмәләрнең, сәламәтлекне саклау өлкәсендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка коммерциягә карамаган оешмаларның үзара хезмәттәшлеген дә кертеп, паллиатив медицина ярдәме күрсәтүне оештыру турындагы нигезләмәдә каралган җиһазлар стандартлары нигезендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карамагындагы медицина оешмаларын махсуслаштырылган паллиатив медицина ярдәмен күрсәтүче структур бүлекчәләре, медицина эшләнмәләре, шул исәптән өйдә файдалану өчен бирелә торган кеше организмы органнары һәм системалары функцияләрен тәэмин итү өчен билгеләнгән медицина әйберләре белән учреждениеләрне җиһазлауга (яңадан җиһазландыруга, җиһазландыруга) җибәрелә (алга таба - тиешенчә медицина оешмалары,медицина эшләнмәләре).

2. Субсидия алу өчен учреждение Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидия бирү кирәклеген нигезләгән аңлатма, субсидия суммасын исәпләүне, шул исәптән медицина эшләнмәләрен сатып алуга беренчел смета, шулай ук тәэмин итүчеләрнең (подрядчыларның, башкаручыларның) тәкъдимнәрен исәпкә алган аңлатманы да кертеп;

сатып алуга планлаштырыла торган медицина эшләнмәләре турында мәгълүмат.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге Тәртипнең 2 пунктының икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән документларны алган көннән алып биш эш көне эчендә учреждение тарафыннан тапшырылган документларны карый һәм субсидия бирү турында йә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Учреждениегә субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

бирелгән документларның бу Тәртипнең 2 пунктының икенче һәм өченче абзацлары нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

учреждение тарафыннан бирелгән документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

4. Учреждениегә бирелә торган субсидия күләме (S) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S = \Sigma(C_i \times T_i),$$

монда:

$C_i$ - медицина эшләнмәләренең тиешле төре саны;

$T_i$ - Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Контрактның башлангыч (максималь) бәясен билгеләү тәртибен, бердәнбер тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) белән төзелә торган контракт бәяләрен һәм товар берәмлегенең, эшнең, медицина эшләнмәләрен сатып алуны гамәлгә ашырганда хезмәт күрсәтүләрнең башлангыч бәясен билгеләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 15 маендагы 450н номерлы боерыгы нигезендә билгеләнә торган медицина әйберләре төренең тиешле берәмлеге бәясе.

5. Субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм учреждение «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк форма нигезендә субсидия бирү турында килешү төзиләр, ул түбәндәге нигезләмәләрне үз эченә ала:

субсидия бирү максатлары;

субсидия бирү нәтиҗәсе зурлыгы;

субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү чаралары планы;

субсидиянең күләме;

субсидия күчерү сроклары (график);

хисаплылыкны тапшыру сроклары;

учреждение тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм сроклары;

килешүгә үзгәрешләр кертү (шул исәптән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына субсидия бирү өчен элегрәк җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары киметелгән очракта) нигезләре һәм тәртибе;

берьяклы тәртиптә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы карары буенча килешүне вакытыннан алда туктату өчен, шул исәптән түбәндәгеләргә бәйле рәвештә, нигезләр:

учреждениене үзгәртеп оештыру (кушу рәвешендә үзгәртеп корудан тыш) яисә бетерү;

әлеге Тәртип һәм (яисә) килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү максатларын һәм шартларын  учреждение тарафыннан бозу;

учреждение тарафыннан килешүне берьяклы тәртиптә өзүне тыю.

Кирәк булганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм учреждение «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасыннан файдаланып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк форма нигезендә килешүгә өстәмә килешү яисә  килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

6. Килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче числосына учреждение туры килергә тиешле таләп -  учреждениедә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар, Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән бюджет инвестицияләрен кире кайтару буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар булмау, федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән очраклардан тыш, үтәлмәгән бурычлар булмау.

7. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе - субсидия акчалары исәбеннән медицина әйберләрен җиһазлауга (яңадан җиһазлауга, җиһазландырып бетерүгә) планлаштырылган медицина оешмаларының гомуми санында фактта җиһазландырылган (яңадан җиһазландырылган, җиһазландырып бетерелгән) медицина оешмалары өлеше, субсидия бирелгән елның 31 декабренә торышы буенча кимендә 100 процент күләмендә.

8. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы килешүдә каралган срокта субсидияне Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган учреждениенең шәхси счетына тулы күләмдә күчерә.

9. Учреждение квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның бишенче эш көненнән  дә да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән формалар буенча финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия  булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү чаралары планын гамәлгә ашыру турында хисап  бирә.

10. Хисап финанс елында файдаланылмаган субсидияләрнең калган акчалары Татарстан Республикасы бюджеты кеременә хисап елыннан соң килүче елның

25 гыйнварыннан да соңга калмыйча кайтарылырга тиеш, моңа Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы агымдагы финанс елында файдаланылмаган әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешүгә субсидия акчаларының калган өлешләрен җибәрүгә ихтыяҗ булу турында карар кабул иткән очраклар керми.

Агымдагы финанс елында файдаланылмаган әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешүгә субсидия акчаларының калган өлешләрен җибәрүгә ихтыяҗ булган очракта, учреждение Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына хисап елыннан соң килүче елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча, агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләр, шулай ук учреждениенең күрсәтелгән йөкләмәләре күләмен (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) раслый торган документларның (документларның күчермәләренең) үтәлмәгән йөкләмәләре барлыгы турында мәгълүмат җибәрә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге пунктның икенче абзацында күрсәтелгән мәгълүматны учреждениедән алган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча агымдагы финанс елында файдаланылмаган әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешүгә субсидия акчаларының калган өлешләрен җибәрүгә ихтыяҗ булу яисә булмавы турында карар кабул итә.

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы агымдагы финанс елында файдаланылмаган әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга ирешүгә субсидиянең калган өлешләрен җибәрүгә ихтыяҗ булу турында карар кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм учреждение арасында мондый карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнелә торган өч көн эчендә килешүгә өстәмә килешү төзелә.

11. Финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган элек медицина оешмасы тарафыннан башкарылган түләүләрне кире кайтарудан кергән акчалар булган очракта, агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге Тәртипнең 1 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен, учреждениенең элек җитештерелгән түләүләрне кире кайтарудан килгән акчалар, шулай ук учреждениенең күрсәтелгән йөкләмәләре булуын һәм күләмен раслый торган документлар (документлар күчермәләре) финанс белән тәэмин итү чыганагы булган үтәлмәгән йөкләмәләре барлыгы турында мөрәҗәгате нигезендә учреждениедән алардан файдалану турында карар кабул итә (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш).

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы әлеге Тәртипнең 1 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен учреждениедән мөрәҗәгать алынган көннән алып биш эш көне эчендә агымдагы финанс елында элек учреждение тарафыннан башкарылган, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган түләүләрне кире кайтарудан керемнәр файдалану турында карар кабул итә.

12. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органы субсидия бирү максатларының һәм шартларының үтәлешен мәҗбүри тикшерүне гамәлгә ашыра.

13. Субсидия Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча ачыкланган субсидия биргәндә билгеләнгән максатларны һәм шартларны учреждение

үтәмәгән очракта, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының тиешле таләпләрен алган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына учреждение тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

Медицина оешмасы тарафыннан субсидия акчасын кире кайтару сроклары бозылганда Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы бу пунктның беренче абзацында билгеләнгән срок тәмамланган көннән 30 көн эчендә субсидия акчасын Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.